**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЛЕНИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ НОВОШЕШМИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

ул. 40 лет Победы, д.32
с.Ленино,423181

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯҢА ЧИШМӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ЛЕНИНС АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

Җиңүнең 40 еллыгы урамы, 32
Ленино авылы,423181

тел.: (8-84348) 3-44-16, факс: (8-84348) 3-44-10; Lenin.Nsm@tatar.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

18 нче ноябрь 2025 ел № 13

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Ленино авыл җирлеге Башкарма комитетының «Яңа Чишмә муниципаль районы Ленино авыл җирлеге башкарма комитеты баш бухгалтерлары һәм бухгалтерларының хезмәтенә түләүне оештыру һәм шартлары турында» 30.04.2019 № 8 карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының «Бюджет өлкәсе хезмәткәренең хезмәт хакын арттыру турында» 27.10.2025 ел, № 03-12/7278 рекомендация хаты нигезендә Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Ленино авыл җирлеге башкарма комитеты баш бухгалтерының социаль гарантияләрен тәэмин итү максатларында, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының Ленино авыл җирлеге башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Ленино авыл җирлеге башкарма комитеты баш бухгалтерлары һәм бухгалтерларының хезмәт хакын түләүне оештыру һәм шартлары турындагы нигезләмәгә, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Ленино авыл җирлеге Башкарма комитетының 30.04.2019 № 8 карары белән (Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Ленино авыл җирлеге Башкарма комитетының 22.10.2020 № 11; 20.05.2024 № 10; 25.10.2024 № 16; 8.04.2025 № 7; карарлары белән кертелгән үзгәрещләр белән) (алга таба – Нигезләмә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Нигезләмәнең 3 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Бухгалтерларның вазифа хезмәт хакы түбәндәге күләмдә билгеләнә:

| Вазифа | Авыл җирлеге башкарма комитетында халык саны 3,5 мең кешегә кадәр булган вазифа хезмәт хакы, сумнарда |
|---|---|
| Баш бухгалтер | 31 000 |

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматларының рәсми порталында»: https://pravo.tatarstan.ru һәм «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникацион челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталында Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында: https://novosheshminsk.tatarstan.ru бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карар 2026 елның 1 январеннан үз көченә керә.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль районы
Ленино авыл җирлеге
Башкарма комитеты җитәкчесе

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЛЕНИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ

С.Ю. Питеркина